**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в состав призывной комиссии Республики Татарстан по мобилизации граждан по должностям и состав призывных комиссий муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан по мобилизации граждан по должностям

В соответствии со статьей 20 Федерального закона от 26 февраля 1997 года № 31-ФЗ «О мобилизационной подготовке и мобилизации в Российской Федерации» **постановляю**:

1. Внести в состав призывной комиссии Республики Татарстан по мобилизации граждан по должностям и состав призывных комиссий муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан по мобилизации граждан по должностям, утвержденные Указом Президента Республики Татарстан от 11 августа 2017 года № УП-698 «О призывной комиссии Республики Татарстан по мобилизации граждан и призывных комиссиях муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан по мобилизации граждан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 9 февраля 2019 года № УП-93, от 15 июня 2019 года № УП-350 и от 11 августа 2020 года № УП-474), следующие изменения:

а) состав призывной комиссии Республики Татарстан по мобилизации граждан по должностям дополнить абзацами следующего содержания:

«заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – Руководитель Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан;

прокурор Республики Татарстан;

военный прокурор Казанского гарнизона.»;

б) состав призывных комиссий муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан по мобилизации граждан по должностям дополнить абзацем следующего содержания:

«прокурор (заместитель прокурора) города (района) Республики Татарстан.».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
30 сентября 2022 года
№ УП-696

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең вазыйфалар буенча составына һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссияләренең вазыйфалар буенча составына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре турында» 2017 елның 11 августындагы ПУ-698 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 9 февралендәге ПУ-93 номерлы, 2019 елның 15 июнендәге ПУ-350 номерлы һәм 2020 елның 11 августындагы ПУ-474 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең вазыйфалар буенча составына һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссияләренең вазыйфалар буенча составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең вазыйфалар буенча составына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе;

Татарстан Республикасы прокуроры;

Казан гарнизоны хәрби прокуроры.»;

б) Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының гражданнарны мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссияләренең вазыйфалар буенча составына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы шәһәре (районы) прокуроры.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 30 сентябрь
№ ПУ-696